СОВЕТ
БОЛЬШЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2017 с. Большие Тиганы № 53

**Об отчете Главы Большетиганского сельского поселения Алексеевского муниципального района за 2016 год**

Заслушав и обсудив доклад Главы Большетиганского сельского поселения «Отчет Главы Большетиганского сельского поселения о социально-экономическом развитии территории за 2016 год и о задачах на 2017 год»

**Совет Большетиганского сельского поселения решил:**

1. Отчет о деятельности Большетиганского сельского поселения утвердить.
2. Совету и исполкому Большетиганского сельского поселения необходимо:
- принять меры по укреплению финансового положения сельского поселения;
- продолжить работу по благоустройству, озеленению и уличному освещению населенных пунктов;
- продолжить работу по ликвидации безработицы среди населения;
- оказать содействие населению в развитии личных подсобных хозяйств и реализации излишков сельскохозяйственной продукции;
- активизировать работу по сбору средств самообложения граждан и эффективно использовать собранные средства.
3. Рекомендовать руководителям учреждений, расположенных на территории сельского поселения эффективно и экономно использовать выделенные бюджетные средства.
4. Обнародовать настоящее решение на информационных стендах Большетиганского сельского поселения Алексеевского муниципального района РТ и разместить на официальном сайте Алексеевского муниципального района Республики Татарстан.
5. Контроль за исполнением данного решения оставляю за собой.

**Глава Большетиганского сельского поселения**
**Алексеевского муниципального района РТ:** **Р.А.Зарипов**

Приложение № 1
к решению Совета
Большетиганского сельского поселения
Алексеевского муниципального района
Республики Татарстан
от 12.01.2017 № 53

Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясенең 2016 елда
социаль – иктисадый үсеше һәм 2017 елга бурычлар турында
авыл җирлеге башлыгының отчеты

Хөрмәтле авылдашлар!

Үзенең мәшәкатьләре белән менә тагын бер ел артта калды. Без бүген сезне Зур Тигәнәле авыл җирлегенең узган 2016 елда эшләнгән эш нәтиҗәләре белән таныштырып үтәрбез.

2015 елда 3 нче чакырылыш депутатларын сайлаганнан соң 2016-2020 елларга йөкләмә кабул ителгән иде. Менә чакырылышның 1 елы узды. Шуңа күрә сүзне 5 еллык планыбызның үтәлешеннән башласак дөрес булыр.

Искә төшерсәк, әлеге планга түбәндәге пунктлар кертелде.

1.Әшнәк авылының ФАПын ремонтлау.

2.Зур Тигәнәле авыл мәдәният йортының фасадын ремонтлау.

3.Әшнәк авылында 300 метр каты түшәлгән юл салу.

4.Зур Тигәнәле авылы зиярәтенең 150 метр коймасын алмаштыру, зиярәттәге агачларны кисү.

5.Зур Тигәнәле авылының М.Вахитов һәм С.Сәйдәшев урамнарында каты түшәлгән юл ясау.

6.Зур Тигәнәле авылында 10 һәм Әшнәк авылында 5 яктырту ноктасы арттыру.

7.Әшнәк клубының эчен ремонтлау.

8.Әшнәк авылында биотермик баз ясау.

9.Әшнәк авылында инеш аша зиярәткә җәяүле басма ясау.

Әшнәк авылында ФАП ремонтлауга килсәк, бу эш өлешчә эшләнде һәм дәвам итә. Әшнәктә 300 метр каты түшәлгән юл салына башлады. Ләкин соңгы катлавы акча җитмәү сәбәпле 2017 елга калдырылды. Зур Тигәнәле авылы зиярәтенең 150 метр коймасы алмаштырылды, агачлар киселде. Зур Тигәнәле авылында 3 һәм Әшнәк авылында 2 яктырту ноктасы арттырылды.

Шулай итеп 9 пунктның 1 тулысынча, 3 се өлешчә үтәлгән. Калган йөкләмәләр өстендә алдагы 4 елда ныклап эшләргә кирәк булачак.

Моннан тыш дәүләт программалары буенча да шактый гына эш планлаштырылган иде.

1.Алексеевский - Биләр трассасыннан мәктәпкә кадәр юлга ремонт ясау.

2.Зур Тигәнәле авылында модулле ФАП салу.

3.Әшнәк авылында авылдан зиярәткә чыгу өчен капиталь буа ясау.

Беренче икесе үтәлде, Әшнәктә буа ясау буенча проект документлары эшләнә.

Авыл җирлеге эшчәнлеге җирлекнең бюджетына бәйле. Бюджетның керем өлешенең планда каралган күләмен карыйк.

Ел башына 2016 елгы бюджет 1 млн. 848 мең 700 сум тәшкил итте. Шуның 717 мең сумы налоглардан керәсе керем иде. Моны аерым саннарда карап үтсәк:

186 мең сум керем салымыннан

111 мең сум милек салымыннан

407 мең сум җир салымыннан

9 мең сум бердәм авыл хуҗалыгы салымыннан

Дотацияләр барлыгы 1 млн 56 мең 100 сум, субвенциялар 75 мең 600 сум.

Ел ахырына фактта үтәлгән керемне карап узыйк.

| Салым төре | План | Факт | Үтәлеш, % |
|---|---|---|---|
| Керем салымы | 117,7 | 117,7 | 100 |
| Бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 11,6 | 11,6 | 100 |
| Җир салымы | 680,9 | 713,5 | 105 |
| Дәүләт пошлинасы | 7,2 | 7,2 | 100 |
| Милек салымы | 113,4 | 113,4 | 100 |

Чыгымнарга тукталып узыйк.

Алар барлыгы 2 млн. 733 мең 400 сум:

- коммуналь чыгымнар барлыгы 382 мең 480 сум
- хезмәт хакына 1 млн. 1 мең 300 сум
- ГСМ га 22 мең сум
- электротоварларга 11 мең 600 сум
- ЗАГСка 500 сум
- төрле эш программаларына 7 мең сум
- Салымнарга 166 мең 97 сум
- 2 клубның ягу системасына техник хезмәт күрсәтүгә, сигнализатор тикшертү, инструктаж өчен 23 мең 450 сум
- яңа ел бәйрәмен уздыруга 8 мең 200 сум
- ел буена сигнализациягә хезмәт күрсәтүгә 23 мең сум
- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Алексеевский районы флагы өчен 2 мең 700 сум
- Кзыл Чишмә авылының зиратына бульдозер хезмәте 10 мең 400 сум
- Әшнәк плотинасын ремонтлауга 24 мең 300 сум

Ә менә үзара салымга тукталып узарга кирәк.

2014 елда 78 мең җыелып республикадан 312 мең өстәлгәч 390 мең сум керем булган иде. Алар барысы да 2015 елда чыгымга куелды. 120 мең юлларны кардан чистартуга, 270 мең җәяүле күперенә китте.

2015 елда 209 мең сум җыелды. 836 мең республика бюджетыннан килде. 75 мең Тигәнәле авылында пожарный гидрант куюга 20 мең Әшнәк авылында пожарный гидрант куюга, 440 мең җәяүле күперен ясауга, 510 мең Әшнәк авылында 300 метр каты түшәлгән юл төзүгә күчерелде.

2016 елда 126 мең 500 сум җыелды. 506 мең республика бюджетыннан килде. 50 мең сумы Зур Тигәнәле авылы зиярәтенең 150 метр коймасын алмаштыруга һәм зиярәттә агачлар кистерүгә. 182 мең сум Әшнәк авылында 160 метр каты түшәлгән юл салуга китте. 400 мең сум җәяүле күперенең ике ягына да каты түшәлгән юл төзергә күчерелде. Ләкин юл салырга 2016 елда өлгермәдек, аукцион гына узып калды, 2017 елда яз эшләнәчәк бу эш.

Хөрмәтле авылдашлар, күз алдыгызда, бюджетка 4 ел эчендә самообложениедән 2 млн. 67 мең 500 сум өстәмә керем керде. Бу кечкенә сумма түгел. Шуңа күрә Президентның 1 гә 4 программасы туктамаса үзарасалымны җыярга кирәк дип саныйм. Ләкин бик авырлык белән бирүче, яки бирмәүче гаиләләр бар. Тавышка килеп тә самообложение алып булмый.

Ә хәзер авыл җирлегенең демографик хәлен карап үтик.

| Халык саны | 2015 | 2016 |
|---|---|---|
| Барлыгы | 721 | 709 |
| Зур Тигәнәле | 567 | 556 |
| Әшнәк | 153 | 152 |
| Кызыл Чишмә | 1 | 1 |

Күреп торабыз халык саны кими. Яшьләр квартиралар алып, өйләр салып район үзәгенә, шәһәрләргә китә. Халыкның кинәт бик күп кимүе моңа кадәр авылда пропискада торып читтә яшәгәннәрнең тораклы булгач гаиләләре белән берьюлы пропискадан төшүененнән дә килеп чыга. Туу да үлем белән чагыштырып карасак, 3 бала туган, 11 кеше үлгән.

Авыл җирлеге территориясендә эшләүче эш яшендәге кешеләрнең 45 се инвестор хуҗалыгында, 44 се бюджетта эшли, безнең территориядә теркәлгән 300 дән артык кеше читкә чыгып эшлиләр.

Хуҗалыклар санын исәпләгәндә:

| | 2015 | 2016 |
|---|---|---|
| Барлыгы | 249 | 250 |
| Тигәнәле | 190 | 191 |
| Әшнәк | 58 | 58 |
| Кызыл Чишмә | 1 | 1 |

Тигәнәледә 1 хуҗалык артты. Бу бер ташландык саналган хуҗалыкта яңа йорт салыну белән бәйле.

Халыкның терлек асравына килсәк

| | 2016 елның 1 нче январе | 2017 елның 1 нче январе |
|---|---|---|
| Мөгезле эре терлек | 334 | 307 |
| Сыерлар: | 127 | 122 |
| Зур Тигәнәле | 112 | 107 |
| Әшнәк | 15 | 15 |

| | | |
|---|---|---|
| Сарыклар | 404 | 376 |
| Атлар | 14 | 12 |
| Кәҗә | 48 | 56 |
| Тавыклар | 1718 | 1893 |
| Умарта | 112 | 88 |

Саннардан күренгәнчә, җирлектә узган елгы белән чагыштырганда мөгезле эре терлекләр саны кимегән. Сыерлар саны да кимүен дәвам итә. Тагын ел буена 5 баш юкка чыккан. Сыерларны төрле сәбәпләр аркасында бетерәләр. Авыру сәбәпле, картаю сәбәпле сыер асрауны ташладылар. Файдасы юк дип бетерүчеләр дә бар. Авыл җирлегендә бөтенләй дә терлек тотмаучы хуҗалыклар елдан ел арта бара. Ләкин арабызда армый – талмый, замана авырлыкларыннан зарланмый күпләп хайван асраучы гаиләләр әле бар. Алар тырышсаң терлек асрап була икәнен исбатлап яшиләр. 8 һәм аннан да күбрәк баш мөгезле эре терлек тотучылар: Нургалиев Рәхим, Акберов Рөстәм, Галимов Фәнил, Яруллин Фәрит, Ахметзянов Салават, Яруллин Наил хуҗалыклары. Тагын 10 гаилә 5 баштан 7 башка кадәр мөгезле эре терлек тота.

Терлек асрау турында сөйләгәндә дәүләт субсидиеләрен әйтеп узарга кирәк. Савым сыерларга һәм кәҗәләргә 405000 сум субсидие бирелсә, атларга 6 гаилә 3шәр мең сум субсидие алдылар. Кошлар алып үстергән 9 гаилә 48180 сум акчаларын кире кайтардылар. Сыерларга ветеринария хезмәтен күрсәтүгә тотылган акчаларыннан 3әр йөз сумны 59 гаилә 105 баш сыерга кайтара алды.

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештереп сатуга килсәк, 2015 елда шәхси хуҗалыклардан 3788 ц сөт сатылган булса, 2016 елда бу сан 2946 ц тәшкил итә. Узган елгыдан 842 ц ким.

Ит тапшыруга килгәндә справкалар буенча:

сыер ите – 83,6 ц

сарык ите – 3,9 ц

ат ите – 16,1 ц

кош ите – 7,45ц сатылган.

Авыл хуҗалыгы турында сөйләгәндә безнең территориядә 3 гаилә фермасы эшләп килә.

Тагын бер җитди мәсьәләбез җир пайлары. 2016 ел өчен фермер хуҗалыклары да, ООО “Хузангаевское” да аренда түләде. Җир пайлары өчен исәп-хисапны ашлык, печән яки акча белән ясадылар.

Тагын бер, елда отчетта кузгата торган мәсьәлә, авылның төзеклеге һәм чисталыгы. Урамнарда, юл буйларында, хуҗасыз йортлар тирәсендә чүп-чарны җыештырабыз. Бу эш җәй буена берничә тапкыр кабатлана. Чүп үләннәре үскәч, янә чалгы, кирәк ише эш кораллары белән авылны чүп үләннәрдән чистартырга чыгабыз.

Авыл җирлеге территориясен яшелләндерү эше дә алып барыла. 2016 елда клуб тирәсендә, инеш буенда, ФАП янында агачлар утыртылды, парк яңартылды.

Урамнардагы төнге утларга тукталып китик. Алексеевский – Биләр трассасы буенча авыл аша узучы федераль линиядәге 66 ноктаны санамыйча ике авылга 58 ноктада ут яна.

Авылыбыз җирлегендә 4 кибет, 1мәктәп, балалар бакчасы, 2 клуб, 2 ФАП, музей, библиотека, почта бүлеге, 2 мәчет эшли.

Традицион бәйрәмнәргә килсәк, Яңа ел, 23 февраль, 8 март, Җиңү бәйрәме, Сабантуй, өлкәннәр көне, әниләр көне кебек бәйрәмнәр уздырылып тора.

Хөрмәтле авылдашлар, мин үземнең докладымда авылның барлык якларын да яктыртырга тырыштым. Алда чыгыш ясаучылар докладка өстәмәләр кертер. Әгәр авыл тормышының кайсы да булса бер ягын сүз уңаеннан төшереп калдырган булсак, сез дә безнең чыгышларны тулыландыра аласыз.